КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2019 ел, 20 май г.Казань № 414

Оешмалар мөлкәтенә салым түләүгә бәйле чыгымнарның бер өлешен каплау өчен махсус икътисадый зоналарның идарә итүче компанияләренә Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибен раслау турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2014 – 2021 елларга Татарстан Республикасының икътисадый үсеше һәм инновацион икътисады» дәүләт программасын раслау турында» 2013 ел, 31 октябрь, 823 нче карары белән расланган «2014 – 2021 елларга Татарстан Республикасының икътисадый үсеше һәм инновацион икътисады» дәүләт программасының «2014 – 2021 елларга Татарстан Республикасында дәүләт икътисад сәясәтен камилләштерү» ярдәмче программасын тормышка ашыру максатларында, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Бу карарга теркәлгән Оешмалар мөлкәтенә салым түләүгә бәйле чыгымнарның бер өлешен каплау өчен махсус икътисадый зоналарның идарә итүче компанияләренә Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибен расларга.
2. Бу карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасының Икътисад министрлыгына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин